**«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И**
**ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ**
**МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«__17__»____.12______2019_ ел** **№__1352__**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
территориясендә муниципаль
җир контролен гамәлгә ашыру буенча
Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
Палатасы тарафыннан 2019 елның
26 нчы июлендәге 612 номерлы
күрсәтмәсе белән расланган
административ регламентка
үзгәрешләр кертү хакында»

ТР Чистай шәһәр прокуратурасының 2019 елның 10 декабрендәге 02-08-02-2019 номерлы муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функциясен үтәүнең административ регламенты протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында гы 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль законга нгезләнеп

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында»гы Чистай муниципаль районының 2019 елның 26 июлендәге 612 номерлы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы күрсәтмәсе белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 1.3 пунктында «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм

индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 294-ФЗ номерлы Федераль закон) ("РФ законнары җыентыгы", 29.12.2008, N 52 (1 бүлек) ст.6249) абзацыннан соң, «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында»гы 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 473-ФЗ номерлы Федераль закон) («РФ законнары җыентыгы», 2015 елның 5 гыйнвары, 1 номер (1 бүлек), ст. 26)» абзацы өстәргә;

2) 1 бүлекнең 1.4 пунктында, икенче абзацтан соң, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Чистай» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә муниципаль җир контроле 294-ФЗ номерлы Федераль закон, 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла. «Чистай» алгарышлы социаль-икътисади үсеш территориясе резидентларына планлы, планнан тыш тикшерүләр үткәрү үзенчәлекләре 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында беркетелгән».

2. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче М.Ю.Исхакова